ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чаралары планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чаралары планын (кушымта итеп бирелә) расларга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2020 елның 22 октябре
№ 636-VI ДС

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының
2020 елның 22 октябрендәге 636-VI ДС номерлы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чаралары планы**

| № т/б | Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы тәкъдимнәр | Гамәлгә ашыру буенча чаралар | Үтәү срогы | Башкару өчен җаваплы |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Бүгенге көндә исән-сау ветераннар турында кайгырту, сугыш еллары вакыйгалары, яу кырларында гомерләрен корбан иткән сугышчылар, җиңү хакына тылда армый-талмый хезмәт куйган һәркем турында хатирәләрне мәңгеләштерү – безнең изге бурычыбыз. | 1.1. Кирәкле ярдәм һәм булышлык күрсәтү максатында депутатларның Бөек Ватан сугышы ветераннары янына барулары | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |
| 2. | 2020 елның 1 июлендә Россия Федерациясе Конституциясенә үзгәрешләр кертү мәсьәләсенә кагылышлы бөтен Россия күләмендә узган тавыш бирү ил тормышында тарихи әһәмияткә ия мөһим иҗтимагый-сәяси вакыйга булды. Дәүләтебез куәтен арттыруга, социаль гарантияләрне ныгытуга хезмәт итүче бөтен ил өчен уртак рухи хәзинәләрне һәм гореф-гадәтләрне саклауга юнәлтелгән төзәтмәләрне татарстанлыларның күпчелеге хуплады. Тавыш бирү йомгаклары илкүләм лидерыбыз – Владимир Владимирович Путин курсын хуплау дәрәҗәсе республикада югары булуын күрсәтте. | 2.1. Россия Федерациясе Конституциясенә төзәтмә хакында «Гавами хакимиятне оештыруның һәм аның эшчәнлегенең аерым мәсьәләләрен җайга салуны камилләштерү турында» 2020 елның 14 мартындагы Россия Федерациясе Законын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән Татарстан Республикасы законнары проектларын әзерләү һәм карау | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары рәисләре |
| 3. | Сайлау кампаниясе барышында күп тәкъдимнәр кертелде. Алар барысы да муниципаль дәрәҗәдәге программаларны һәм республика программаларын гамәлгә ашырганда исәпкә алынырга тиеш. Хакимият органнарыннан кешеләр бүгенге көндә аларның ачык һәм | 3.1. Беркетелгән округларда эшләү, гражданнарны кабул итү, гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | аңлаешлы булуын, үзләрен борчыган мәсьәләләрдә ярдәм күрсәтүен көтә. Фикерләрнең үзебезгә ошаганнарына гына түгел, бәлки һәрберсенә игътибар бирергә, аларны эш барышында исәпкә алырга һәм гражданнарга үз карашларыбызны дәлилләп җиткерә белергә тиешбез. Хакимият органнарына халык белән эшләүнең заманча барлык ысулларын үзләштерү шарт. Бу безгә урыннардагы хәлләрнең чынбарлыктагы торышын белергә, тиз арада карарлар кабул итәргә, эшне җиренә җиткереп башкарырга ярдәм итәчәк. | | | |
| 4. | Республикада яшәүче һәр халыкның мәдәниятен, үзенчәлеген саклау һәм үстерү, милләтара һәм динара татулык тотрыклы тормышыбызның нигезен тәшкил итә һәм безгә ышанычлы адымнар белән алга барырга мөмкинлек бирә. | 4.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының күчмә утырышында «Мәдәни диалогны үстерүдә туган телнең роле» мәсьәләсен карау (Актаныш муниципаль районы мисалында) | 2021 елның мае | А.Р. Зарипов |
| 5. | Балаларны һәм яшьләрне үзара ихтирам һәм милли-мәдәни үсеш рухында тәрбияләүгә аерым игътибар бирергә, аларның туган телне һәм мәдәниятне өйрәнүгә кызыксыну белдерүен хупларга кирәк. Шундый проектларның берсен «Яңарыш» республика фонды гамәлгә ашыра. Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең зирәк җитәкчелегендә татар, рус һәм инглиз телләрендә белем бирелә торган «Адымнар» полилингваль мәгариф комплекслары төзелә. | 5.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының күчмә утырышында «Татарстан Республикасында полилингваль белем бирүне үстерү перспективалары турында»гы мәсьәләне «Адымнар – белемгә һәм килешүгә юл» полилингваль комплексы» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе базасында карау | 2020 елның IV кварталы | А.Р. Зарипов |
| 6. | Республикада яшәүче барлык милләт вәкилләренең – татарларның, русларның, чувашларның, удмуртларның, мордваларның, мариларның һәм башка халыкларның телен һәм мәдәниятен саклау өчен барлык шартларны булдырырга тиешбез. Әлеге мәсьәләгә һәм | 6.1. Татарстан Республикасында яшәүче барлык милләт вәкилләренең туган телләрен танытуга юнәлдерелгән социаль әһәмияткә ия чараларда катнашу.<br>6.2. «Татарстан Республикасында милли белем бирүне үстерү концепциясе» | ел дәвамында<br><br>2021 елның I кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары<br><br>М.Г. Әхмәтов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | республиканың күпмилләтле халкының берләшүенә зур әһәмият биреп, киләсе елны Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан итәргә дигән тәкъдим кертәм. | мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе утырышы.<br>6.3. «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру барышы турында»гы мәсьәлә буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе утырышы. | 2021 елның III кварталы | М.Г. Әхмәтов |
| 7. | Бөтен Россия күләмендә халык санын алу киләсе елда мөһим вакыйгаларының берсе булачак. Республика Хөкүмәтенә, муниципаль берәмлекләр башлыкларына тиешле аңлату эшләре алып барып, бу эштә җәмәгатьчелекнең актив катнашуын тәэмин итеп, аны иң югары дәрәҗәдә оештыруны йөклим. | 7.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты утырышында «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм уткәрү буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы законы проектын карау | 2020 елның октябре | А.Г. Хәбибуллин |
| 8. | Яңа шартларда безгә чит илләр белән урнаштырылган барлык элемтәләрне саклап калырга, аларны республика мәнфәгатьләрен кайгыртуда яңа мөмкинлекләр ачу өчен кулланырга кирәк. Моннан тыш, Россия төбәкләре белән төрле юнәлешләрдәге, шул исәптән эчке туризмны үстерү буенча да, хезмәттәшлекне киңәйтү шарт. | 8.1. Татарстан Республикасы шәһәрләренең «Иҗади шәһәрләр челтәре» ЮНЕСКО проектында катнашулары» темасына «түгәрәк өстәл» | 2021 елның сентябре | А.Р. Зарипов |
| 9. | Эшебездә без кешеләрнең мәнфәгатьләрен кайгыртуга, яшәү өчен уңайлы мохит булдыруга зур өстенлек бирәбез. Республика | 9.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты утырышында «2030 | 2021 елның апреле | Л.Н. Шәфигуллин |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | программалары һәм илкүләм проектлар нәкъ менә шушы максатларны күздә тотып гамәлгә ашырыла. Илебез Президенты Владимир Владимирович Путинның илкүләм максатлар турындагы Указын гамәлгә ашыру кысаларында безгә үзебезнең үсеш программаларына төзәтмәләр кертергә кирәк булачак. Шул ук вакытта республиканың 2030 елга кадәр үсеш стратегиясе нигезендә безнең төп бурычларыбыз үзгәрешсез кала.<br>Безнең эшебез халыкның үз тормышыннан ни дәрәҗәдә канәгать булуыннан чыгып бәяләнә. 10 ел эчендә социаль- мәдәни объектларның 7,5 меңнән артыгы тәртипкә салынды һәм 3200 дән артык яңа объект төзелде, 400 дән артык җәмәгать урыннары булдырылды, 12 меңнән артык йортта капиталь төзекләндерү уздырылды.<br>Елдан-ел безнең шәһәрләр һәм авыллар матурлана бара. Без бу масштаблы эшне республика программалары һәм милли проектлар кысаларында дәвам итәчәкбез.<br>Татарстанлылар паркларны һәм яр буйларын, мәйданнарны һәм бульварларны төзекләндерү концепциясенә кагылышлы фикер алышуда актив катнаштылар. Бүген без бу объектларның кешеләргә хезмәт итүен, республика халкы һәм кунаклар аларга бик теләп йөрүен күреп торабыз. Болар – Татарстаныбызга күркәмлек өстәүче, аның үз йөзен булдыручы урыннар. Мондый эшне без дәвам иттерәчәкбез. | елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе»н гамәлгә ашыру барышы турында»гы мәсьәләне карау.<br>9.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетында «Территорияләрне төзекләндерү буенча бишьеллык комплекслы программаны гамәлгә ашыру йомгаклары турында (Яшәү өчен уңайлы мохит булдыру)» мәсьәләсен карау.<br>9.3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы «Бердәм Россия» фракциясе утырышында «Территорияләрне төзекләндерү буенча бишьеллык комплекслы программаны гамәлгә ашыру йомгаклары турында (Яшәү өчен уңайлы мохит булдыру)» мәсьәләсен карау. | <br>2021 елның I кварталы<br><br>2021 елның II кварталы | <br>А.В. Тыгин<br><br>Ю.З. Камалтынов |
| 10. | Моннан тыш, якындагы елларда без күпфатирлы йортларның 6,5 меңнән артык ишегалдын төзекләндерәчәкбез. Быел планда – 1000 объект. Туплаган тәҗрибәбез, һөнәр һәм | 10.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты утырышында «Татарстан Республикасында | 2021 елның II кварталы | А.В. Тыгин |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | күнекмәләребез төзекләндерү эшләре белән комплекслы шөгыльләнергә – яңартылган мәдәният йортлары, яр буйлары, парклар, ишегаллары үзара бәйләнгән һәм юллар белән тоташтырылган булуын тәэмин итәргә мөмкинлек бирә. Без кешеләрнең поликлиникага, мәктәпкә, балалар бакчасына, китапханәгә, тукталышка ничек һәм нинди тротуарлар буенча баруы, балаларның ишегалдында имин уйнавы, әти-әниләрнең вакытны уңайлы үткәрә алуы турында уйлыйбыз. Торак төзелеше өлкәсендә илкүләм проектны кабул итү нәтиҗәсендә безнең алга җитди бурычлар куелды. Бу эшне торакны файдалануга тапшыруны арттыру максатыннан чыгып кына түгел, бәлки социаль тирәлек, транспорт, инженерлык тирәлеге объектларын төзүне, шулай ук эш урыннары булдыруны да күздә тотып, комплекслы итеп башкарырга кирәк. Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә Муниципаль берәмлекләр башлыклары советы белән берлектә агломерацияләр өчен территорияләрне планлаштыруның бердәм документларын әзерләүне тәэмин итәргә, шулай ук әлеге территорияләрне комплекслы үстерүгә идарәнең нәтиҗәле алымнарын эшләргә кирәк. | территорияләрне комплекслы үзләштерү проблемалары һәм нечкәлекләре. Закон аспектлары» мәсьәләсен карау | | |
| 11. | Башлангыч медицина-санитария ярдәме күрсәтү өлкәсендә матди-техник базаны яхшыртуны дәвам итәргә, онкология белән чирләүче балаларны дәвалау өчен яңа ысуллар кулланыла торган үзәк, Чаллыда һәм Әлмәттә Республика клиник онкология диспансеры филиалларын, Әлмәт балалар шәһәр хастаханәсенең хирургия корпусын, шулай ук Казанда күз авыруларын | 11.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты утырышында «Гражданнарга амбулатория-поликлиника шартларында башлангыч медицина-санитария ярдәме күрсәтү өлешендә Татарстан Республикасында законнарны гамәлгә ашыру турында»гы мәсьәләне карау. | 2021 елның июле | С.М. Захарова |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | дәвалау хастаханәсе һәм башка шундый заманча медицина объектлары төзергә ниятебез бар. Башлангыч баскыч медицина учреждениеләрен хезмәткәрләр белән тәэмин итү элеккечә үк көнүзәк мәсьәлә булып тора. | 11.2. Казан шәһәрендә офтальмология үзәге төзү проектын гамәлгә ашыру мониторингы | ел дәвамында | Х.Г. Миргалимов |
| 12. | Медицина тармагын цифрлы технологияләр нигезенә кору шулай ук мөһим бурыч булып тора. Бу эш иң беренче нәүбәттә төрле белешмәләрне һәм тикшеренү узган авыруларга табиб бәяләмәләрен тиз арада тапшыру мөмкинлеге кебек мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән булырга тиеш. Дәүләт һәм хосусый медицина учреждениеләренең электрон медицина карталары булдырылган бердәм цифрлы контурын төзү шарт. | 12.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты утырышында «Сәламәтлек саклау өлкәсендә цифрлы технологияләр кертү өлешендә «Сәламәтлек саклау» илкүләм проектын гамәлгә ашыру турында»гы мәсьәләне карау | 2021 елның феврале | С.М. Захарова |
| 13. | Моннан тыш, хәзерге шартларда югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүнең кичектерелгән процедураларын, авыруларны планлы төстә хастаханәләргә салу юнәлешендә үтәләсе эшләрне тәмамларга кирәк. | 13.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты утырышында «Гражданнарга стационар шартларда медицина ярдәме күрсәтү өлешендә законнарны Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру турында»гы мәсьәләне карау. | 2020 елның декабре | С.М. Захарова |
| 14. | Халыкның диспансерларда тикшеренү узуына аерым игътибар бирелергә тиеш. | 14.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты утырышында «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге халыкка диспансеризация уздыруны оештыру турында»гы мәсьәләне карау | 2020 елның ноябре | С.М. Захарова |
| 15. | Ә сәламәтлекне саклау өчен аны ныгытудан, дөрес яшәү рәвеше алып барудан, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүдән дә нәтиҗәлерәк башка берни дә була алмый. | 15.1. «Татарстан Республикасының кече елгаларында экологик һәм танып белү туризмын үстерү» темасына «түгәрәк өстәл» | 2020 елның ноябре | А.Р. Габделҗанов, «ТНВ» депутат төркеме |
| 16. | Быел без өстәмә рәвештә зур 8 спорт объекты төзедек, соңгы айда түбәле 4 футбол манежы | 16.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты | 2021 елның марты | С.М. Захарова |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | файдалануга тапшырылды. Хәзер яшь футболчылар һәм регбичыларга үзләре яраткан спорт төре белән ел әйләнәсендә шөгыльләнү мөмкинлеге бар. Безгә киләчәктә дә халыкның төрле катлау вәкилләре шөгыльләнсен өчен спорт корылмалары төзү эшен дәвам иттерергә кирәк. | утырышында «Татарстан Республикасында балалар-яшүсмерләр спортын үстерү турында»гы мәсьәләне карау | | |
| 17. | Балаларның һәм яшьләрнең җәйге ялын оештыру да аларның сәламәтлеген ныгыту эшенә күркәм этәргеч бирә. | 17.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты утырышында «Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең җәйге ялын оештыру турында»гы мәсьәләне карау | 2021 елның мае | С.М. Захарова |
| 18. | Шунысын да әйтеп үтәсем килә: яшьләрнең барлык төркемнәре белән эшләү, аларның һәрберсенә идеяләрен тормышка ашыру һәм уңышка ирешү өчен үзенең иң күркәм сыйфатларын, сәләтен күрсәтергә мөмкинлек бирү бик зур әһәмияткә ия. | 18.1. Яшьләр иҗтимагый оешмалары вәкилләре катнашында «Татарстан Республикасында ихтыярый эшчәнлек турында»гы мәсьәлә буенча «түгәрәк өстәл» | 2021 елның июне | С.М. Захарова,<br>Н.К. Шимина |
| 19. | Яшьләргә үз мөмкинлекләреннән файдалану өчен шартлар тудыру эшен һичшиксез дәвам иттерергә кирәк. Нәкъ менә яшьлек чорында кеше шәхес буларак формалаша һәм, ахыр чиктә, яшәү һәм үсеш өчен тормышта үз урынын билгели. Яшьләр үз язмышларын республика белән бәйләсен өчен без барысын да эшләргә тиешбез. | 19.1 Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламентының һәм Калининград өлкә Думасы Яшьләр парламентының яшь белгечләр мәнфәгатьләренә кагыла торган мәсьәләләр буенча видео-конференц-элемтә режимында уртак утырышы | 2021 елның IV кварталы | С.М. Захарова,<br>Н.К. Шимина |
| 20. | Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле, социаль яктан якланмаган һәм ярдәмгә мохтаҗ гражданнар, төрле сәбәпләр аркасында авыр тормыш хәлендә калган кешеләр һәрвакытта да даими игътибар үзәгендә булырга тиеш. Безнең тарафтан тормышка ашырыла торган барлык проектларда да иң беренче чиратта аларның мәнфәгатьләрен күз алдында тоту зарур. | 20.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты утырышында «Татарстан Республикасында халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә (инвалидларның яшәү-көнкүрешендә ярдәмне оештыру өлешендә) законнарны гамәлгә ашыру турында»гы мәсәләне карау | 2021 елның ноябре | С.М. Захарова |
| 21. | Әлеге эшне башкарганда безгә, | 21.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы | 2021 елның | А.Р. Зарипов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | архитектурабызны һәм гореф- гадәтләребезне саклаган хәлдә, заманча алымнарны активрак файдаланырга кирәк булачак. Иң мөһиме – безнең мәдәни объектларыбыз һәркем өчен уңайлы, теләп йөри торган урын булырга тиеш. Яңартылган милли китапханә моңа ачык мисал. Анда китап саклау һәм заманча җәмәгать урыны функцияләре берләшә. | Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының күчмә утырышында «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 2019 елның 6 августындагы 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру барышы хакында»гы мәсьәләне Татарстан Республикасы Милли китапханә базасында карау | ноябре | |
| 22. | Укытучыларыбызга ярдәм йөзеннән илебез Президенты йөкләмәсе нигезендә яңа уку елыннан башлап мәктәпләребездәге 23 меңнән артык сыйныф җитәкчесенә бишәр мең сум акча түләү каралган. Шул ук вакытта без төбәк дәрәҗәсендәге кызыксындыру чараларын да саклап калдык. Моннан тыш, 1 сентябрьдән башлангыч сыйныф укучыларының барысы да түләүсез, сыйфатлы кайнар ризык белән тәэмин ителә. Бу – 209 мең мәктәп укучысы дигән сүз. | 22.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Социаль сәясәт комитетының уртак утырышында «Башлангыч сыйныф укучыларын түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру турында»гы мәсьәләне карау | 2021 елның феврале | А.Р. Зарипов, С.М. Захарова |
| 23. | Икътисадның реаль секторы таләпләренә җавап бирердәй мәгариф даирәсе булдыру максатында Татарстанда 41 ресурс үзәге төзелде. Монда белем алу өчен барлык шартлар булдырылды, яңа җиһазлар, шул исәптән Worldskills чемпионатыннан мирас булып калган җиһазлар да урнаштырылды. Ресурс үзәкләре эшче кадрлар әзерләү белән генә чикләнмичә, һөнәри белем бирүне үстерүдә гаять зур роль уйнаучы учреждениеләргә әверелде. | 23.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Социаль сәясәт комитетының уртак утырышында «Татарстан Республикасында кадрлар әзерләү буенча һөнәри белем бирә торган ресурс үзәкләре эшчәнлеге турында»гы мәсьәләне «Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогика колледжы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе базасында карау | 2021 елның марты | А.Р. Зарипов |
| 24. | Бизнеска ярдәм күрсәтү инфраструктурасы, шул исәптән 5 махсус социаль-икътисадый үсеш территориясе эшлеклелеклекне һәм инвестицияләр кертү өлкәсендәге активлыкны арттыруга көчле этәргеч бирә (аларның резидентлары тарафыннан бюджетка кертелгән акча | 24.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты утырышында «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең сәнәгать мәйданчыкларын үстерү проблемалары һәм перспективалары» | 2021 елның Июне | Л.Н. Шәфигуллин |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | ташламалар бәясеннән ике тапкырга артып китте инде). Алабуга махсус икътисадый зонасы илдәге шундый зоналар арасында хосусый инвестицияләр күләме, эш урыннары саны буенча беренче урында тора. Иннополис актив үсештә. Күптән түгел генә монда Росатом белән берлектә мәгълүматлар эшкәртү буенча Идел буендагы иң зур үзәкне төзү буенча 8 млрд сумлык проект тормышка ашырыла башлады. 2004 елда «КАМАЗ»ның буш торучы мәйданнарын файдалану проекты буларак үз эшчәнлеген башлап җибәргән «Мастер» Кама индустриаль паркы бүгенге көндә 1,4 млн кв. метр мәйданда урнашып, Европаның иң зур индустриаль паркларының берсенә әйләнде. Элеккеге сәнәгать зоналарын яңартуның уңышлы мисалы буларак «Химград» технопаркын күрсәтергә була.<br>Кызганыч, инфраструктураларның барысы да бизнес өчен нәтиҗәле эшләми. Районнарда сәнәгать паркларындагы кайбер урыннар бөтенләй файдаланылмый, кайберләрендә анык идарә структурасы юк, резидентлар җәлеп итү буенча системалы эш алып барылмый, алар тиешле инфраструктура белән тәэмин ителмәгән. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына, район башлыклары белән берлектә, сәнәгать парклары һәм мәйданчыклары эшенең нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләүне һәм аларны тормышка ашыруны йөклим. Безнең төп бурычыбыз – эшкуарлар өчен, кече һәм урта бизнесны үстерү өчен уңайлы шартлар булдыру. Күпләр моны әлегә кадәр тулысынча аңлап бетерми. Үз эшеңне башлап җибәрү, яңа | турындагы мәсьәләне карау (муниципаль берәмлекләрнең берсе мисалында)<br>24.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты утырышында «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2017 елның 2 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру хакында»гы мәсьәләне карау.<br>24.3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты утырышында «Кече һәм урта бизнеска күрсәтелә торган ярдәм чаралары комплексы (коронавирус пандемиясе шартларында)» контроль мәсьәләсен карау | 2021 елның III кварталы<br><br>2021 елның III кварталы | Л.А. Якунин<br><br>Л.А. Якунин |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | производстволар ачу, эш урыннары булдыру – чын мәгънәсендә, олы хөрмәткә һәм дәүләт ярдәменә лаеклы зур хезмәт. Әлеге максатларда республикада финанслар белән тәэмин итү, белем бирү, милек мәсьәләләренә кагылышлы, шулай ук базарларга юл ачу кебек ярдәм чараларының тулы бер комплексы гамәлгә ашырыла. | | | |
| 25. | Аерым алганда, Татарстанда Россиянең иң зур компанияләре – «Вайлдберриз» һәм «Озон»ның яңа мәйданчыкларында республиканың ике меңнән артык товар сатучысы эшли. Бездә шулай ук үзебезнең «Казан экспресс» дигән интернет- мәйданчыгыбыз уңышлы гына эшләп килә, бу елның ахырына ул 70 кә якын товар бирү пункты ачуны планлаштыра. Республика маркетинг үзәге югары нәтиҗәләргә иреште. Аның мәйданчыгында 3 меңнән артык товар сатучы оешма 30 млрд сумнан артык керем алуга иреште. | 25.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты утырышында «Вайлдберриз», «Озон» һәм башка шундый Россия эре компанияләренең яңа мәйданчыкларын ачуның республика икътисадын үстерүгә йогынтысы» контроль мәсьәләсен карау | 2021 елның II кварталы | Л.А. Якунин |
| 26. | Икътисадның динамикалы үсеше күп очракта продукция җитештерүнең барлык циклларына бәйле процессларның цифрлы нигезгә корылу дәрәҗәсенә бәйле. Сәнәгатьтә ясалма интеллект нигезендә цифрлы технологияләрне кулланышка кертү тиз арада иң уңышлы бизнес-карарлар кабул итәргә, җитештерү чыгымнарын киметергә, хезмәт җитештерүчәнлеген һәм компаниянең базарда конкурентлыкка сәләтен арттырырга мөмкинлек бирә.<br>Хөкүмәткә, тулаем алганда, цифрлы нигезгә күчүне тәэмин итү өчен төп тармакларны цифрлаштыруны иң югары дәрәҗәсенә җиткерү буенча карарлар эшләргә, бу тармакның һәрберсен цифрлаштыруның торышына, | 26.1. Татарстан Республикасының Цифрлы трансформация концепциясен әзерләүдә катнашу.<br>26.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты утырышында «Татарстан Республикасының Цифрлы трансформация концепциясен әзерләү һәм аны гамәлгә ашыру барышы турында»гы мәсьәләне карау | 2021 елның марты | Л.Н. Шәфигуллин |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | кадрларның әзерлегенә бәя бирергә кирәк. | | | |
| 27. | Экология мәсьәләләренә, аерым алганда, елга, күлләребезнең һәм сусаклагычларыбызның торышына кагылышлы мәсьәләгә аерым тукталып үтәсем килә. Татарстан территориясенең 7 процентын сулыклар тәшкил итә.<br>Моннан тыш, предприятиеләр экологик иминлекне тәэмин итүне җитди контрольдә тотарга тиеш. Бүгенге көндә республика предприятиеләрендә чистарту корылмаларының 80 процентка якыны норматив таләпләренә җавап бирми. Хуҗалык субъектларының һәм тиешле хакимият органнарының әлеге мәсьәләне хәл итүдә катгый чаралар күрүен сорыйм. | 27.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында «Татарстан Республикасы территориясендәге су объектларын саклауга һәм яклауга юнәлдерелгән федераль, республика һәм муниципаль программаларны үтәү барышы турында»гы мәсьәләне карау | 2021 елның июле | А.К. Хамаев |
| 28. | Республикада миллионга якын кеше авыл җирендә яши. Без авылларда тормышны яхшырту буенча, шул исәптән республика программалары кысаларында, зур эш алып барабыз.<br>Агросәнәгать комплексы өлкәсендә авыл хуҗалыгы җитештерүенең нәтиҗәлелеген арттыру буенча эшне дәвам иттерергә кирәк. | 28.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышларында «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын үтәү турында»гы мәсьәләне карау | квартал саен | А.К. Хамаев |
| 29. | Соңгы елларда республикада крестьян (фермер) хуҗалыкларына һәм шәхси хуҗалыкларга булышлык күрсәтүнең тулы бер системасы эшләнде.<br>Тулаем алганда, бүген без фермерлык хәрәкәтенә нигез салу этабын уздык дип әйтергә мөмкин. Аны киләчәктә тагын да үстерү – киләсе унъеллыкка бурычыбыз булып тора. Һәрбер фермерлык хуҗалыгы авылның һәм кешеләрнең ышанычлы таянычы булырга тиеш. | 29.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышларында «Авыл халкының эшлеклелек активлыгын арттыру турында»гы мәсьәләне карау.<br>29.2. «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре проблемалары һәм селекция эше турында» темасына «түгәрәк өстәл» | квартал саен<br><br><br><br><br><br>2021 елның апреле | А.К. Хамаев<br><br><br><br><br><br>Х.Г. Миргалимов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Үз чиратында, хакимият органнары фермерларның барлык башлангычларына һәръяклап булышлык күрсәтергә тиеш. Әлеге юнәлештә авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру буенча Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшин һәм Марат Готыф улы Әхмәтов җитәкчелегендә алып барылган эш иң күркәм мисал булып тора. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының әлеге уртак эше дәвамлы булыр, дип ышанам. | | | |
| 30. | Икътисадтагы уңышлар транспорт инфраструктурасының үсеше белән тыгыз бәйләнгән. М-7 автомобиль юлының Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап, Кама күпере аша уза торган участогын, шулай ук Казан шәһәренең көньягыннан Идел күпере аша салыначак югары тизлектәге М-12 трассасын, «Шәле- Баулы» автомобиль магистрален, Зур Казан боҗрасының икенче чиратын һәм метрополитенның икенче линиясен төзү эшен тәмамлау әлеге юнәлештә башкарылачак стратегик проектлар булып тора. Болар белән беррәттән транспорт инфраструктурасы объектларын төзекләндерү, торак пунктларыбызны асфальт юлларга тоташтыру, фермерлык хуҗалыкларына керү юллары салу эшен дәвам иттерәчәкбез. Әлеге барлык проектлар, иң беренче чиратта, гражданнарның тормышын яхшыртуга юнәлтелгән. | 30.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты утырышында «Татарстан Республикасының магистраль инфраструктурасын модернизацияләүнең һәм киңәйтүнең комплекслы планы турында»гы мәсьәләне карау | 2021 елның III кварталы | А.В. Тыгин |
| 31. | | 31.1. Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасы нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Дәүләт | ел дәвамында | Ю.З. Камалтынов, Х.Г. Миргалимов, А.Р. Габделҗанов, Т.П. Ларионова |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Советындагы депутатлар берләшмәләре тарафыннан гамәлгә ашыру (аерым планнар буенча) | | |